ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 3-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 3-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 27 сентябре
№ 58-VII ДС

3-7 номерлы проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); 2015, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 73 (часть I), «Россия Федерациясенең башка субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы» сүзләрен «Россия Федерациясенең башка субъекты закон чыгару органы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә:

**2 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенә (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары, Татарстан Республикасы законнары нигезендә оештырылучы башка Татарстан Республикасы дәүләт органнары (алга таба шулай ук – дәүләт органнары) аппаратларында гамәлгә ашырыла.».

**3 статья**

«Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 статьясындагы 4 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), «(Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре)» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**4 статья**

«Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24 статьясындагы 4 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 3 (II өлеш); 2005, № 3 (I өлеш); 2008, № 5 (II өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8, № 12; 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), «(Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре)» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 95 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (1 өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 21 статьяның 5 өлешендә:

а) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр тиешле муниципаль берәмлек чикләрен билгеләү турында Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көннән соң бер ай эчендә муниципаль берәмлектә яшәүчеләрнең җирле референдум уздыру турында федераль законда һәм Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә төзелгән сайлау хокукына ия төркеме җирле референдум уздыру турындагы инициатива белән чыкса, яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча җирле референдум уздырыла. Күрсәтелгән төркем муниципаль берәмлекнең сайлау хокукына ия яшәүчеләренең гомуми саныннан кимендә 3 проценты күләмендә имзалар җыюны оештырырга һәм имза кәгазьләрен җирле референдум уздыру турында федераль законда һәм Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырырга тиеш. Җыелган имзаларның дөреслеген тикшерү, җирле референдум уздыру датасын билгеләү, шулай ук муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең җирле референдум уздыру буенча «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләр сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнар нигезендә төзелгән референдум комиссиясе тарафыннан башкарыла. Җирле администрациянең җирле референдум уздыруны матди-техник тәэмин итү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә ашыра.»;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына сайлауларны билгеләү һәм сайлауларны үткәрү буенча «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләр сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнар нигезендә төзелгән сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла. Яңа төзелгән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органына сайлаулар уздыруны матди-техник тәэмин итү буенча вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты гамәлгә ашыра.»;

2) 22 статьяда:

а) $2^1$ өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$2^1$. Әлеге статьяның 2 өлешендәге икенче абзацында каралган җирлектә җирлекнең сайлау хокукына ия халкы саны 300 кешедән арткан очракта, җирлекнең вәкиллекле органы сайлана. Җирлекнең вәкиллекле органы депутатлары саны һәм аларның вәкаләтләре срогы халык тарафыннан гражданнар җыенында билгеләнә. Әлеге җирлекнең вәкиллекле органына сайлауларны билгеләү һәм сайлауларны үткәрү буенча «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законда, башка федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган бүтән вәкаләтләр сайлаулар һәм

референдумнар турындагы законнар нигезендә төзелгән сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.»;

б) 8 өлешнең 12 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

3) 28 статьяны үз көчен югалткан дип танырга.

**6 статья**

«Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (I өлеш); 2007, № 12 (I өлеш); 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 7; 2015, № 7 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш), 2023, № 27 (I өлеш), өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Административ-территориаль төзелешне үзгәртү мәсьәләләре буенча мондый үзгәртү турындагы тәкъдимне истә тотып тавыш бирүне әзерләү һәм үткәрү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның йөкләмәсе буенча тиешле территория комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла, тавыш бирүне үткәргәндә алар «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган референдум комиссиясе вәкаләтләрен башкара.».

**7 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 22 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш) «(Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең иң югары башкарма органнары җитәкчеләре)» сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**Статья 8**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 2 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5; 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 1 (I өлеш); 2019, № 2

(I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), 2023, № 92 (I өлеш); 2024, № 47 (I өлеш), беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2. Әлеге Законның даими нигездә муниципаль вазыйфалар биләгән затларны пенсия белән тәэмин итү өлешендә гамәли көче муниципаль берәмлекләрнең тиешле сайлау комиссияләрендә даими штат нигезендә эшләгән сайлау комиссияләре әгъзаларына кагыла».

**9 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 47 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяның 2 өлешендә «муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә эшләүче һәм юридик затлар булучы сайлау комиссияләренең (алга таба – муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре) хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 статьяның 3 өлешендә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе» сүзләрен төшереп калдырырга;

3) 6 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы – муниципаль берәмлек уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органында җирле үзидарә органы яисә муниципаль вазыйфа биләүче зат вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча бурычлар даирәсе билгеләнгән вазыйфа.»;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре,» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 3 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 7 статьяның 3 өлешендә «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре аппаратларында» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 12 статьяның 2 өлешендә «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

6) 13 статьяның 1 өлешендәге 5 пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 14 статьяның 1 өлешендәге 4 пунктында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

8) 15 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Җирле үзидарә органы җитәкчесе, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары булып торучы муниципаль хезмәткәр тиешле вазыйфаларны биләү чорында мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы һөнәри берлек органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен белдерә алмый.»;

9) 16 статьяның 1 өлешендә:

а) 2 пунктның «в» пунктчасында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 пунктта:

«а» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен «җирле үзидарә органында» сүзләренә алмаштырырга;

«б» пунктчасында «муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен «җирле үзидарә органында» сүзләренә алмаштырырга;

в) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) үзе муниципаль хезмәт вазыйфасын били торган йә турыдан-туры буйсынган яисә аның контрольлегендә булган җирле үзидарә органында өченче затлар эшләре буенча ышанычлы зат яисә вәкил булырга, әгәр федераль законнарда башкасы каралмаган булса;»;

г) 5 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 6 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен һәм «, сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 9 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе һәм аларның җитәкчеләре» сүзләрен «һәм аның җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

10) $16^1$ статьяда:

а) 1 өлештә «муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен «җирле үзидарә органында» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «,муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен «җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

в) 5 өлештә «,муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе» сүзләрен «җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга;

г) 10 өлешнең 3 пунктында «,муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органында, сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен «җирле үзидарә органында» сүзләренә алмаштырырга;

11) 17 статьяда:

а) 8 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 9 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 22 статьяда:

а) 1 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлештә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычлары, хокуклары һәм җирле үзидарә органы эшчәнлеген җайга сала торган акт, җирле үзидарә органының структур бүлекчәсенең бурычлары һәм функцияләре, муниципаль хезмәтнең шунда биләнә торган вазыйфасының функциональ үзенчәлекләре нигезендә вазыйфаи бурычларын үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылыгы;»;

6 пунктта «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратындагы» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) 27 статьяның 2 өлешендә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен һәм «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

14) 36 статьяда:

а) 2 өлештә «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы бетерелгән очракта, аның шәхси эшнамәсе, саклау өчен, бетерелгән җирле үзидарә органы функцияләре тапшырылган җирле үзидарә органына, яисә аның хокук варисына тапшырыла.»;

15) 2 нче кушымтада:

а) 6 пунктның унөченче абзацында «, сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 7 пунктта:

тугызынчы абзацта «, сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) 8 пунктның алтынчы абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

г) 13 пунктның өченче абзацында «, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 14 пунктта:

өченче абзацта «, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «, сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 15 в пунктта:

өченче абзацта «, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «, сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 16 пунктта:

өченче абзацта «, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «, сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

з) 17 пунктта:

өченче абзацта «, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «, сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

16) 4 нче кушымтада:

а) 1 пунктта «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләрендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 5 пунктның беренче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

г) 6 пунктның беренче абзацында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

д) 9 пунктның 4 пунктчасында «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының» сүзләрен төшереп калдырырга;

е) 13 пунктта «, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

ж) 15 пунктның икенче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты» сүзләрен төшереп калдырырга;

з) 21 пунктның беренче абзацында «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең» сүзләрен төшереп калдырырга;

и) муниципаль хезмәткәрләрне аттестацияләү турындагы Үрнәк нигезләмәгә кушымтада «(муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе)» сүзләрен төшереп калдырырга.

**10 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

«Татарстан Республикасының
аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан
Республикасы законы проектына аңлатма

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2024 елның 8 августындагы 232-ФЗ номерлы Федераль закон белән федераль закон актларыннан муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә кагылышлы нигезләмәләр төшереп калдырылды (чөнки «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 мартындагы 60-ФЗ номерлы Федераль закон белән 2023 елның 1 гыйнварыннан муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре сайлау комиссияләреннән чыгарылды).

Шуңа бәйле рәвештә закон проекты Татарстан Республикасы закон актларыннан шулай ук муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләренә кагылышлы нигезләмәләрне төшереп калдырырга тәкъдим итә.

Тиешле үзгәрешләр түбәндәгеләргә кертелә:

– «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына;

– «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 7 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына;

– «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына;

– Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына.

Шулай ук закон проекты белән «Татарстан Республикасында кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында» 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертелә.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм (яисә) башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә чыгымнар таләп итми.